Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

Менделеевск ш.

05.03.2026 ел № 31

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2023елның 30 октябрендәге 216 нчы номерлы карарының үз көчен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлары турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 469-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Менделеевск районы Прокурорының 2026 елның 17 февралендәге 02-08-02-2026 номерлы протестын карап,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү, алардан файдалану һәм саклау тәртибен раслау турында» 2023 елның 21 октябрендәге 216 нчы номерлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru “Норматив документлар” бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының законлылыкны, хокук тәртибен, кеше хокукларын һәм депутат этикасын үтәү буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары Л.К. Галеева